| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 28 марты** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 03-03-710** |

Кадастр номеры 16:49:010210:0074 булган җир кишәрлеген түбәндәге адрес буенча тартып алу турында: ТР, Зеленодольск шәһәре, Тынычлык урамындагы 14 нче номерлы йорттан һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларыннан якынча, көньяк-көнбатышка таба, 24 метр ераклыкта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 номерлы карары белән расланган 2013-2017/елларга Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы программаны гамәлгә ашыру максатларында, 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы “Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында” Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 49, 56.2, 56.3, 56.6, 56.7, 56.8, 56.9 ст., 2014 елның 31 декабрендәге 499-ФЗ номерлы "РФ Җир кодексына һәм РФ аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 279 ст., 281, РФ ГК, 26 ст., "Татарстан Республикасының “Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 44 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР, Зеленодольск шәһәре, Тынычлык урамындагы 14 нче йорттан 24 метр ераклыкта урнашкан кадастр номеры 16:49:010210:0074 булган җир кишәрлеген, шулай ук әлеге җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алырга.
2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы А.Н Коршуновка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) карар кабул ителгән көннән алып 10 (ун) көн дәвамында урнаштырырга. Зеленодольск муниципаль районы уставында муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен

билгеләнгән тәртиптә тартып алу турында карар бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

3. «ЗМР җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МУ, тапшыру турында хәбәрнамә белән, тартып алына торган күчемсез мөлкәтне алу турындагы карар күчермәсен хат белән җибәрергә. Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы органга тартып алу турындагы карарның күчермәсен җибәрергә.

4. «ЗМР җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм тартып алына торган мөлкәт күләмнәрен бәяләүне, шулай ук сатып алына торган күчемсез мөлкәткә (мена очрагында) бәя бирүне тәэмин итәргә.

5. "ЗМР җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы" МУ кул кую өчен күчемсез мөлкәтне тартып алу турында килешү проектын әзерләргә һәм җибәрергә.

6. Карарның үтәлешен, тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин